ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» апреля 2026 ел № 104

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча виртуаль укыту-консультация пункты булдыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 27 маендагы 159 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча виртуаль укыту-консультация пункты булдыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 27 маендагы 159 номерлы карарына түбәндәге узгәрешләрне кертергә:

- 1 бүлекнең 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгерҗе муниципаль районы халкына табигый һәм техноген характердагы ГО һәм гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә мәгълүмат җиткерү һәм консультация бирү, шулай ук мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган хәвеф-хәтәрләрдән яклау ысулларын, хәбәр итү сигналлары буенча эш итү тәртибен, беренче ярдәм күрсәтү алымнарын, коллектив һәм индивидуаль яклау чараларыннан файдалану кагыйдәләрен, янгын куркынычсызлыгы һәм су юлларында яшәүче кешеләрнең куркынычсызлыгы кагыйдәләрен мөстәкыйль өйрәнү;».

2. «Татмедиа» АҖ филиалы - Әгерҗе районының «Әгерҗе хәбәрләре»(«Агрызские вести») газетасына әлеге карарны «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести» ) район газетасында бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**